ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1428 «13» 11 2017 ел

2017-2021 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районы торак - коммуналь хуҗалыгы
өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан
әзерләү һәм квалификациясен күтәрүнең
муниципаль планын раслау турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә предприятиеләр һәм башка оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен кадрлар белән тәэмин итү системасын һәм шартларны булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 14 декабрендәге № 2941-р күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрү буенча муниципаль планны (алга таба – План) расларга.

2. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә эшләүче предприятиеләргә һәм башка оешмаларга 2017-2021 елларга кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә, ул планны үз акчалары хисабына финанслауны тәэмин итә.

3. Муниципаль район башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитетының беренче урынбасары Р.К. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Э. Фәттәхов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
«13»11 2017 ел, №1428 карарына
кушымта

2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак - коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрүнең муниципаль планы

| | |
|---|---|
| Планның исеме | 2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак - коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрүнең муниципаль планы |
| Планны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон; 2016 елның 14 декабрендәге 2941-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе; Мамадыш муниципаль районы Уставы |
| Планның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Планны эшләүче | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Планның максаты | Мамадыш муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә (алга таба - торак-коммуналь хуҗалык) предприятиеләр һәм башка оешмалар (алга таба - предприятиеләр) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту. |
| Планның бурычлары | Муниципаль берәмлекнең торак-коммуналь комплексы белән идарә итү һәм эксплуатацияләүнең нәтиҗәле системасын формалаштыру;<br>укыту системасын кадрлар сәясәтенең нәтиҗәле формасына, ТКХ предприятиеләрен идарә итү һәм эксплуатацияләүнең заманча формалары һәм методларының теоретик белемнәрен һәм практик күнекмәләрен алуның мөһим факторына әйләндерү;<br>ТКХ предприятиеләре эшчәнлеген оптималь оештыру-хокукый тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>ТКХ предприятиеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеген планлаштыру, финанслау, стимуллаштыру һәм бәяләүнең яңа ысулларын кертү;<br>ТКХ предприятиеләренең ачыклыгын тәэмин итү;<br>ТКХ предприятиеләре өчен квалификацияле кадрлар сайлап алуның нәтиҗәле ысулларын куллану, ТКХ предприятиеләре |

| | |
|---|---|
| | хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләү, шулай ук аларның вазыйфаи (хезмәттә) үсеше өчен шартлар тудыру;<br>ТКХ предприятиеләре хезмәткәрләренең мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау һәм чишү механизмнарын кертү, шулай ук ТКХ предприятиеләре хезмәткәрләренең һөнәри этикасы мәсьәләләрен законнар белән җайга салу;<br>ТКХ объектлары белән идарә итү системасын үстерүне тәэмин итү. |
| Планны гамәлгә ашыру сроклары | 2017 – 2021 еллар |
| Планны башкаручылар | Мамадыш муниципаль районының ТКХ өлкәсендә эшләүче предприятиеләр, тармакта кадрлар әзерләүне, яңадан әзерләүне гамәлгә ашыручы мәгариф үзәкләре (килештерү буенча). |
| Планны финанслау чыганаклары һәм күләме | Финансирование плана осуществляется за счет собственных средств предприятий ЖКХ.<br>Общие расходы на реализацию плана составят 195,0 тыс. рублей, в том числе:<br>2017 ел – 39,0 мең сум.<br>2018 ел – 39,0 мең сум<br>2019 ел – 39,0 мең сум<br>2020 ел – 39,0 мең сум<br>2021 ел – 39,0 мең сум |
| Планны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең югары сыйфатына ирешү. |
| План үтәлешен контрольдә тоту системасы | План чараларын тормышка ашыруны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота |

## 1. Проблеманың характеристикасы

Әлеге План Торак-коммуналь тармак реформасының мөһим өлеше булып тора һәм формалаштыруга юнәлдерелгән чараларны килештереп үткәрүне тәэмин итә:

ТКХ өчен кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү системалары;

ТКХ өлкәсендә намуслы, нәтиҗәле эшләүче предприятиеләр базары;

күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү өчен шартлар.

Торак - коммуналь өлкә предприятиеләренең эш нәтиҗәлелеген күтәрү күбесенчә эшче һәм белгечләрнең эш сыйфатларына бәйле, алар өчен һөнәри төп һәм өстәмә белем квалификация таләбе булып тора.

2017 елның 1 гыйнварына Мамадыш муниципаль районының торак-коммуналь өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр саны 262 кеше тәшкил итә, шул исәптән:

идарәче компанияләр хезмәткәрләре-25 кеше.;

торак фондын эксплуатацияләүче һәм аңа хезмәт күрсәтүче оешмалар хезмәткәрләре-18 кеше; көнкүреш калдыкларын чыгаруны һәм утильләштерүне гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләре – 79 кеше.;

торак фондын капиталь ремонтлаучы оешмалар хезмәткәрләре-25 кеше.;

ресурслар белән тәэмин итүче предприятиеләр оешмалары хезмәткәрләре-109 кеше; шулардан су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу предприятиеләре хезмәткәрләре-56 кеше, җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләр хезмәткәрләре ("зур энергетика" предприятиеләрен исәпкә алмыйча) - 53 кеше.;

районны тышкы төзекләндерү буенча эшчәнлек алып баручы оешма хезмәткәрләре-6 кеше;

Мамадыш муниципаль районының торак-коммуналь өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең гомуми саныннан 86 кеше профильле белемгә ия, ягъни 32,8 %, соңгы биш елда 78 кеше яңадан әзерлек яки квалификация күтәрү курслары узган, ягъни 91,0 %.

Квалификация күтәрү һәм яңадан әзерләү чыгымнарын финанслау предприятиеләр акчалары хисабына башкарылды.

Шуның белән бергә, ТКХ хезмәткәрләрен һәм белгечләрен укытуга һәм яңадан әзерләүгә күбрәк игътибар бирергә кирәк.

Кадрларның квалификация дәрәҗәсенә карата булган таләпләр өзлексез белем бирү системасын ныгыту һәм камилләштерү зарурлыгына бәйле. Даими уку һәм кадрларның квалификациясен күтәрү тармакта уңышлы үзгәрешләр булдыру өчен мөһим шарт.

Идарәче кадрларны укыту-кадрлар ресурсына инвестицияләрнең мөһим төре.

## 2. Планның максатлары һәм бурычлары

Планның максаты булып түбәндәгеләр тора:

җитәкчеләр, белгечләр, ТКХ эшчеләренең һөнәри дәрәҗәсен өзлексез күтәрүгә юнәлдерелгән кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру;

кадрлар әзерләү һәм яңадан әзерләү системасын булдыру юлы белән ТКХ предприятиеләренең нәтиҗәле эшен тәэмин итү;

ТКХ объектларын идарә итү һәм эксплуатацияләү чыгымнарын оптимальләштерү;

кадрлар әзерләүнең, яңадан әзерләүнең һәм квалификация күтәрүнең норматив хокукый базасын үстерү;

торак-коммуналь өлкә хезмәткәрләренең уку системасын укыту-методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итүне камилләштерү.

Планның бурычлары:

муниципаль берәмлекнең ТКХ белән идарә итү һәм эксплуатацияләүнең нәтиҗәле системасын формалаштыру;

укыту системасын кадрлар сәясәтенең нәтиҗәле формасына әверелдерү, ТКХ предприятиеләрен идарә итүнең һәм эксплуатацияләүнең заманча формалары һәм методларының теоретик белемнәрен һәм практик күнекмәләрен алуда мөһим фактор;

ТКХ предприятиеләре эшчәнлеген оптималь оештыру-хокукый тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

ТКХ предприятиеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеген планлаштыру, финанслау, стимуллаштыру һәм бәяләүнең яңа ысулларын кертү;

ТКХ предприятиеләренең ачыклыгын тәэмин итү;

ТКХ предприятиеләре өчен квалификацияле кадрлар сайлап алуның нәтиҗәле ысулларын куллану, аларның эшчеләренең эшчәнлек нәтиҗәләрен бәяләү, шулай ук аларның вазыйфаи (хезмәт) үсеше өчен шартлар тудыру;

ТКХ предприятиеләре хезмәткәрләренең мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау һәм чишү механизмнарын кертү, шулай ук ТКХ предприятиеләре хезмәткәрләренең һөнәри этикасы мәсьәләләрен законнар белән җайга салу;

ТКХ объектлары белән идарә итү системасын үстерүне тәэмин итү.

## 3. Планны ресурслар белән тәэмин итү

ТКХ предприятиеләре хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, һөнәри әзерлеген һәм яңадан әзерләү планы чараларын финанслау ТКХ предприятиеләренең үз акчалары хисабына башкарыла.

2017-2021 елларга планны финанслау күләме 195,0 мең сум тәшкил итә (шул исәптән: предприятиеләрнең үз акчалары – 195,0 мең сум).:

2017 елда – 39,0 мең сум
2018 елда – 33,0 мең сум
2019 елда – 33,0 мең сум;
2020 елда – 37,0 мең сум
2021 елда – 37,0 мең сум

Объемы финансирования мероприятий Плана ежегодно подлежат уточнению в установленном порядке при формировании проекта бюджета на соответствующий финансовый год.

## 4. Планны тормышка ашыру механизмы һәм аның үтәлешен контрольдә тоту

Планны тормышка ашыруда катнашуга Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнары, торак-коммуналь өлкәсе предприятиеләре һәм оешмалары җәлеп ителә (килештерү буенча).

Планны гамәлгә ашыру барышында кадрларның квалификациясен күтәрү, һөнәри әзерлек эшчәнлеген координацияләүне Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тәэмин итә, ул ел саен, финанс чаралары планын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган максатчан күрсәткечләрне һәм программа чаралары буенча чыгымнарны, «ТКХ предприятиеләренең кадрлар исәбендә» программ продуктында төгәлләштерә.

Планның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра , алар «ТКХ предприятиеләренең кадрлар исәбен» программ продуктында кадрлар потенциалының торышына мониторинг үткәрәләр, торак-коммуналь өлкә хезмәткәрләренең Сыйфатлы составына анализ ясыйлар, ел саен «күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге»РНП СРО белән килештерелгән укыту-мәгариф үзәкләрендә белем алу һәм квалификация күтәрү өчен хезмәткәрләр исемлеген төзиләр ТР".

## 5. Планны тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Планны тормышка ашыру нәтиҗәсендә тәэмин ителергә тиеш:
районда торак-коммуналь өлкә кадрларын әзерләү һәм квалификациясен күтәрүнең өзлексез процессы системасын булдыру;
ТКХ өчен кадрлар әзерләүне финанс-икътисадый тәэмин итүне камилләштерү өчен нигез булдыру;
хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү механизмнарын кертү юлы белән торак-коммуналь өлкә хезмәткәрләренең кадрлар составын яхшырту максатларында кадрлар сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру;
эшчеләр санын оптимальләштерү.

| 2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрү буенча муниципаль план» | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күрсәткеч исеме | Кеше саны | Шул исәптән еллап | | | | |
| | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Укытылырга тиешле ТКХ хезмәткәрләренең гомуми саны | 75 | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 |
| Программаны тормышка ашыруга кирәкле акчалар күләме, шул исәптән мең сум.: | 195,0 | 39 | 39 | 39 | 39 | 39 |
| ТКХның үз (предприятиеләре һәм башка оешмалары) | 195,0 | 39 | 39 | 39 | 39 | 39 |

2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрү буенча муниципаль план»

| Профессиональ әзерлек, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү программасының исеме | Укытылырга тиешле ТКХ хезмәткәрләре саны, кеше. | Шул исәптән айлар буенча | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | май | июнь | июль | август | сентябрь | октябрь | ноябрь | декабрь |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| Казан операторларының квалификациясен күтәрү | 29 | | | | 29 | | | | |
| Слесарь КИП һәм АГУ квалификациясен күтәрү | 3 | | | | 3 | | | | |
| Су алу операторларының квалификациясен күтәрү | 9 | | 3 | | | 3 | | | 3 |
| Электр монтерының квалификациясен күтәрү | 3 | | | | 3 | | | | |
| Электр-газ белән эретеп ябыштыручының квалификациясен күтәрү | 6 | | | | 6 | | | | |
| Токарь квалификациясен күтәрү | 5 | | | | 5 | | | | |
| ИТРНЫҢ җитәкче составы өчен хезмәтне саклау | 8 | | | | 8 | | | | |
| КФЙ техник эксплуатацияләү, КФЙ капиталь ремонт үткәрүне оештыру | 12 | 3 | | | | | 3 | 3 | 3 |